ГЛАВА МЕМДЕЛЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422728, Республика Татарстан, Высокогорский район,,
с.Мемдель, ул.Кооперативная, 30

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МӘМДӘЛ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
422728, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Мәмдәл авылы, Кооператив ур.,30

Тел./факс: +7(84365) 60-2-37, e-mail: Memdel.Vsg@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**28 октябрь 2024 ел** **№ 11**

**Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Биектау муниципаль районы Мәмдәл авыл җирлегенең Мәмдәл һәм Юртыш торак пунктларында гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлеге Уставының 22 статьясы һәм 2019 елның 23 октябрендәге 162 номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мәмдәл авыл җирлеге составына керә торган торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» карары нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мәмдәл авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мәмдәл авыл җирлегенең Мәмдәл торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2024 елның 28 ноябрендә 11.00 сәгатькә түбәндәге адрес буенча: Мәмдәл авылы., Кооператив ур., 30 й. (Мәмдәл авыл мәдәният йорты) билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге сорауны расларга:

«2025 елда яшәү урыны буенча теркәлгән һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мәмдәл авыл җирлегенең Мәмдәл торак пункты территориясендә даими яшәүче балигъ булган, СВО да катнашкан кешеләрдән һәм аларнын гаилә әгъзалары һәм 90 яшьтән узган өлкәннәрдән тыш, Һәр кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә, алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә, түбәндәге эшләрне башкаруга:

- су башнясы урнаштыруга
- материал сатып алуга һәм зиратны киртәләүгә
- агачлар кисугә
- тракторга өстәмә җиһаз сатып алуга

юллау белән килешәсезме?

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»

2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Юртыш авыл җирлегенең Мәмдәл торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2024 елның 28 ноябрендэ 15.00 сәгатькә түбәндәге адрес буенча: Юртыш авылы., Кооператив ур., 34а й. (Юртыш авыл клубы) билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге сорауны расларга:

«2025 елда яшәү урыны буенча теркәлгән һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мәмдәл авыл җирлегенең Юртыш торак пункты территориясендә даими яшәүче балигъ булган, СВО да катнашкан кешеләрдән һәм аларнын гаилә әгъзалары һәм 90 яшьтән узган өлкәннәрдән тыш, Һәр кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә, алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә, түбәндәге эшләрне башкаруга:

- су башнясы территориясен киртә белән әйләндереп алуга;
- гидрант урнаштыруга;
- су башнясына насос сатып алуга;
- урам яктырткычларын ремонтлауга

юллау белән килешәсезме?

«ӘЙЕ» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ авыл җирлекләре бүлегендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Авыл җирлеге башлыгы Ф.Г. Сафиуллин